СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**

«08» октябрь 2019 ел

**КАРАР**

№ 161

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану соравы буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясының 1 пункты, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Чепья авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Чепья авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану соравы буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2019 елның 20 сентябрендәге 156 номерлы Чепья авыл җирлеге Советының карары, «Чепья авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану соравы буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2019 елның 20 сентябрендәге 79 номерлы Чепья авыл җирлеге башкарма комитетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге территориясендә 2019 елның 01 декабренә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану соравы буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«Чепья авыл җирлегендә яшәүче 18 яше тулган һәм референдумда тавыш бирергә хокукы булган гражданнарга 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул җыелган акчаларның түбәндә күрсәтелгән урындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына Сез ризамы:

- Арбор авылында: урам-юл челтәрен һәм юлларның асфальт-бетон катламын норматив халәткә китерү;

- Сырья авылында: урам-юл челтәрен һәм юлларның асфальт-бетон катламын норматив халәткә китерү; спорт мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру һәм төзекләндерү, коймалап алу;

- Иске Чепья авылында: балалар уен мәйданчыгын сатып алу, урнаштыру һәм төзекләндерү, коймалап алу;

- Тагашур авылында: Колхозная урамындагы күперне ремонтлау; спорт мәйданчыгын сатып алу, урнаштыру һәм төзекләндерү, коймалап алу;

- Мельничная авылында: зират коймасы эшләтү; урам-юл челтәрен һәм юлларның асфальт-бетон катламын норматив халәткә китерү;

- Чепья авылында: урам-юл челтәрен һәм юлларның асфальт-бетон катламын норматив халәткә китерү; Школьная урамында тротуар җәйдерү; ял паркын төзекләндерү, инвентарь һәм җиһазлар сатып алу, урнаштыру.

**ӘЙЕ** **ЮК**».

3. Аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны экономия барлыкка килгән очракта, Чепья авыл җирлеге Советы карары нигезендә янга калдырылган акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.

4. Әлеге карарны «Хезмәт» район газетасында һәм Татарстан Республикасының pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, Чепья авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Чепья авыл
җирлеге башлыгы А.Г. Нотфуллин